| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2026 п.г.т. Алексеевское № 138

**Электрон документлар рәвешендә**
**башкарма документлар алып бару турында**

Төзелеш тармагында цифрлаштыру максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда башкарма документация составын һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2023 елның 16 маендагы 344/пр номерлы боерыгына, Россия Федерациясендә региональ үсеш буенча Хөкүмәт комиссиясе Президиумы (штабы) утырышының 2025 елның 25 декабрендәге 207пр номерлы дәүләт һәм муниципаль заказчыларны кәгазьдә кабатламыйча гына электрон документлар рәвешендә башкарма документацияне мәҗбүри алып баруга күчерү өлешендәге беркетмәсенә, «Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә башкарма документация булдыру һәм алып бару үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 декабрендәге 1751 номерлы карарына,Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К. Нигъмәтуллин тарафыннан расланган 2026 елга төзелеш өлкәсендә дәүләт заказчысы проектлары белән идарә итүнең мәгълүмати системасында (ИСУП)Татарстан Республикасы муниципаль заказчылары эшен оештыру буенча чаралар планына («Юл картасы») туры китереп

**карар бирәм:**

1. Җирле бюджетлар акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 1.5 өлешендә каралган башкарма документларны формалаштыру һәм алып бару тәэмин ителәә, муниципаль контрактка кертелгән кәгазь чыганакта электрон документлар рәвешендә, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү эшләрен башкаруны күздә тота, башкарма документларны электрон рәвештә булдыру һәм алып бару буенча подрядчы (башкаручы) йөкләмәләре тәэмин ителә дип билгеләргә.
2. Муниципаль заказчыларга тәкъдим итәргә:

2.1. җирле бюджетлар акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү) буенча муниципаль контрактларга кәгазьдә кабатланмыйча гына электрон документлар рәвешендә башкарма документлар төзү һәм алып бару буенча подрядчының (башкаручының) йөкләмәләрен кертергә;

2.2. җирле бюджетлар акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү) буенча электрон документлар рәвешендә башкарма документлар булдыруны һәм алып баруны тәэмин итәргә;

2.3. проектлар белән идарә итүнең мәгълүмати системасында (ИСУП) башкарма документация алып бару эшен оештырырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Е.Н.Мельниковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**